КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 декабрь г.Казань № 1241

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 апрель, 214 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 апрель, 214 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1 һәм 2 пунктларда «авыл җирлегендә» сүзләреннән соң «, шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә» пунктын 4 пункт дип санарга;

әлеге карар белән расланган Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау тәртибендә:

исемендә «авыл җирлегендә» сүзләреннән соң «, шәһәр тибындагы поселокларда» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәрвакыт авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары

белән билгеләнгән Һәрвакыт авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) бирү чыгымнарын финанслау механизмын билгели.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин